МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.03.2021 г.Казань № 171

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 20 апрелендә 7648 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү
өлкәсендә дәүләт хезмәтләре
күрсәтүнең аерым административ
регламентларына үзгәрешләр
кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2021 елның 30
мартындагы 171 номерлы
боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 26 гыйнварындагы 46 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 11.07.2016 №401, 08.06.2017 №349, 18.05.2018 №383, 24.09.2018 №897, 04.02.2019 №77, 07.08.2019 №598, 14.11.2019 №1008, 08.05.2020 №289, 14.07.2020 №515, 08.10.2020 №709 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2 бүлектә:

2.4 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүчеләрнең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү бурычларны түләп бетергәнчегә кадәр туктатыла, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көннән дә артыграк булмаган чорга гына.»;

2.5 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Банкта яисә башка кредит учреждениесендә ачылган хосусый счет реквизитларын күрсәтеп, әлеге Регламентның 1 нче кушымтасындагы форма буенча ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында гариза, ул электрон имза укыгычларны кулланып имзаланырга мөмкин.

2. Затның әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән граждан категорияләренә каравын раслаучы документларның күчермәләре.

3. 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарында каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән хезмәт ветераннары, «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре

турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган затлар өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлегеннән үзләренең 2018 елның 31 декабренә федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүе турындагы белешмәне тапшыра.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмалардан – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә дә алына.

Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итүләрен раслый торган документны күрсәтә.

Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге хезмәткәре тарафыннан таныклана.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлегенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закондагы (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш»;

2.6 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара багланыш каналлары буенча вәкаләтле органнардан белешмәләр алына:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында;

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләү алудан баш тарту турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычлар булуы (булмавы) турында;

төрләренең исемлеге 542 номерлы Нигезләмәгә кушымтада күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының дүртенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән затларга айлык түләү билгеләнгән очракта).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Үзәк мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «542 номерлы Нигезләмәнең 2.10 пункты» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.7 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу.

2. Мөрәҗәгать итүченең яшәү урынына карамаган Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать итүе»;

2.8 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булуы дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып тора.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның документлар белән мөрәҗәгать итүе;

әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән затларның 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 4-7 статьяларында билгеләнгән нигезләрдә яки федераль законнар нигезендә социаль ярдәм чараларын алуы, «Чернобыль АЭС һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә айлык акчалата түләү билгеләнү очракларыннан тыш;

гражданинның тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыруы;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;

мөрәҗәгать итүчеләрнең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча айлык акчалата түләү билгеләү турында сорап мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынмаса»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «542 номерлы Нигезләмәнең 2.1 пункты, 542 номерлы Нигезләмәнең 10.6 пункты» сүзләрен «542 номерлы Нигезләмәнең 2.1, 2.5, 10.6 пунктлары» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

3.1.1 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) юлга айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында карар әзерләү;»;

3.4.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Юлга айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне вәкаләтле органнардан сората:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләү алудан баш тарту турында;

542 номерлы Нигезләмә кушымтасында төрләренең исемлеге күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычлар булуы (булмавы) турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»

3.5-3.6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Юлга айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында карар әзерләү

3.5.1. Үзәк бүлеге белгече әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, алынган белешмәләр һәм әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда алынган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат вәкаләтләрен тикшерү;

әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булу-булмавын тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен кирәкле, әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентка 3 нче, 6 нчы кушымталар нигезендәге формалар буенча электрон рәвештә айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яисә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын рәсмиләштерә;

айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын электрон рәвештә Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза кую өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган көннән ике эш көне эчендә, әмма гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар проекты.

3.5.2. Үзәк бүлеге җитәкчесе айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар проектын карый һәм, электрон санлы имза белән имзалап, Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документларны айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проекты җибәрелгән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар.

3.5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында белдерү

Үзәк бүлеге белгече дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан айлык акчалата түләү билгеләү

турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карарга кул куйганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.5.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү яки айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү

3.5.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү туктатып торылган вакыт эчендә мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы турында белешмәләре алынса яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән бурычны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылган очракта, Үзәк бүлеге белгече:

әлеге Регламентка 6 нчы кушымта нигезендәге форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында карар проектын электрон рәвештә рәсмиләштерә;

әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча айлык акчалата түләү билгеләү турында карар проектын рәсмиләштерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү һәм айлык акчалата түләү билгеләү турындагы карар проектларын Үзәк бүлеге җитәкчесенә имзалу өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычның булмавы яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан бурычларны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү һәм айлык акчалата түләү билгеләү турында карарлар проектлары.

3.5.4.2. Мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычларны җайга салмаган очракта, айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза биргән көннән соң 90 көн эчендә, Үзәк бүлеге белгече айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тарту турында карар проекты әзерли һәм Үзәк бүлеге җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура айлык акчалата түләү билгеләү турындагы гаризаны биргән көннән соң 90 көн узгач, аннан соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тарту турында карар проекты.

3.5.4.3. Үзәк бүлеге җитәкчесе дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында һәм айлык акчалата түләү билгеләү турында карар проектларын яисә айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тарту турында карар проектын карый һәм электрон санлы имза белән имзалый һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында һәм айлык акчалата түләү билгеләү турындагы карар проектларына яисә айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тарту турындагы карар проектына кул куелганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү һәм айлык акчала түләү билгеләү яки айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тарту турында карарлар.

3.5.4.4. Үзәк бүлеге белгече дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан айлык акчалата түләү билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында карарга кул куелганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Үзәк бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына юллап) айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында хәбәр җиткерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә айлык акчалата түләү субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар җибәрү.»;

3.8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Техник хатаны төзәтү әлеге Регламентка 5 нче кушымтадагы форма буенча, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турындагы документны яки мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документны (әгәр андый документлар бирелгән булса) теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза тапшырылган очракта гамәлгә ашырыла.»;

3.8.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.1. Үзәк бүлеге белгече:

техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы);

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турындагы карарны яисә айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерә»;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны яисә айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны имзалау өчен электрон рәвештә Үзәк бүлеге җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар яисә айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында электрон рәвештә Үзәк бүлеге җитәкчесенә имзалау өчен җибәрелгән карар.»;

3.8.2 пунктта:

беренче абзацта «үзгәртеп рәсмиләштерелгән» сүзләреннән соң «дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында карар яки» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «үзгәртеп рәсмиләштерелгән» сүзләреннән соң «дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында карар яки» сүзләрен өстәргә;

3.8.3 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.3. Үзәк бүлеге белгече дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында яисә айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар турында мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язмача, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр итеп, яисә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында яисә айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар турында Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына юллап) хәбәр итә.»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар яки айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итү, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны яки айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына юллау.».

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Үзәк бүлегенә, Үзәккә яки Министрлыкка кергән шикаять ул кергән көненнән соңгы икенче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органга яисә югары торучы органга (андый булган очракта) килгән шикаять аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә каралырга тиеш.»;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ай саен бирелә торган акчалата
түләүне билгеләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

«Республика матди ярдәм
(компенсация түләүләре) үзәге»
ДКУ №____ бүлегенә

_______________________________________
(муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА №_____
_________ 20__ ел.

Мин,____________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
түбәндәге адрес буенча яши:

___________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексы, телефоны, электрон почта адресы)

| Шәхесне раслаучы документ исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

Эш итү нигезе:

___________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен яклауны раслаучы документ реквизитлары)
«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә айлык акчалата түләү билгеләвегез турында үтенәм

_______________________________________________________ ____________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)
СНИЛС (алучыныкы) __________________
Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

Билгеләнгән түләүләрне түбәндәгечә түләүне сорыйм:
счетка күчерү юлы белән __________________________________________

(мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)

почта элемтәсе оешмалары аша ______________________________

(мөрәҗәгать итүченең яисә аның законлы вәкиленең почта бүлекчәсе реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге, аларны үз эченә алган документларның төп нөсхәләре өчен җаваплылык турында һәм социаль ярдәм чараларын түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычлары белән таныштым ______________________

(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

Мәгълүмат алу, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында мәгълүмат алуга риза:

әлеге адрес буенча язмача формада______________________________

түбәндәге телефонга смс-хәбәр итеп ______________________________

(телефон номеры)

әлеге электрон почта адресына электрон документ формасында _______________

Мөрәҗәгать итүче:_________________________________ «__»______ 20__ ел.

(Мөрәҗәгать итүченең ФИА) (имза)

Яңа вакытка социаль ярдәм чараларын автомат рәвештә билгеләү белән килешәм

Мөрәҗәгать итүче:______________________ _________ «__»______ 20__ ел.

(мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А.) (имза)

---

Аеру линиясе

Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү номеры ____

Документлар саны ___ берәмлек, ___ биттә

Документларны кабул итте ________ ________ _______________ _____________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ай саен бирелә торган акчалата түләүне билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №____ бүлегенә

______________________________

(муниципаль районында (шәһәр округында)

Айлык акчалата түләү билгеләү турында карар

№____ «__» ____________

Мөрәҗәгать итүченең ФИА ______________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы ____________________________________

Билгеләргә (бирергә):

| № | Социаль ярдәм чаралары | Түләү күләме | Билгеләнү датасы | Түләү вакыты ___ башлап __________ кадәр |
|---|---|---|---|---|
| | _____ __[1] «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә айлык акчалата түләү | | | ___ башлап __________ кадәр |

Түләү ысулы ________________________________________________
Республика матди ярдәм
(компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ
№___ бүлеге җитәкчесе

_________________________

_________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) ________________ ______________
(Ф.И.А.) (имза)

мөһер урыны
«Республика матди ярдәм (компенсация
түләүләре) үзәге» ДКУ ___ номерлы
бүлеге белгече

______________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) ________________ ______________
(Ф.И.А.) (имза)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):[2]
язмача____________________________________________
почта адресы буенча
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп _________________________________
телефон номеры

---

[1] "Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында" 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының тиешле статьясы яки статьясы һәм тиешле пункты күрсәтелә
[2] Айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проекты электрон рәвештә формалаштырылганда әлеге позиция тутырылмый.

әлеге электрон почта адресына электрон документ формасында

________________________
Электрон почта адресы
бүлек белгече ______________________________ __________________________
(Ф.И.А.) имза

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлегенә
___________________________________________
___________________________________________
(муниципаль районында (шәһәр округында)

Айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тарту турында карар

№___________ «___» ______________

Мөрәҗәгать итүченең ФИА ___________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы _________________________________________________

_____ __[3] «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тартырга.
Баш тарту сәбәбе:

__________________________________________________________________

«Республика матди ярдәм
(компенсация түләүләре) үзәге»
ДКУ №___ бүлеге җитәкчесе
______________________________
____________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) ___________________ __________________
(Ф.И.А.) (имза)

мөһер урыны
«Республика матди ярдәм (компенсация
түләүләре) үзәге» ДКУ ___ номерлы
бүлеге белгече
____________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) _____________________ __________________
(Ф.И.А.) (имза)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):
язмача_____________________________________________________
почта адресы буенча

[3] "Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында" 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының тиешле статьясы яки статьясы һәм тиешле пункты күрсәтелә

түбәндәге телефонга смс-хәбәр итеп ________________________________________

телефон номеры

әлеге электрон почта адресына электрон документ формасында____________________

Электрон почта адресы

бүлек белгече ____________________________________ _______________

(Ф.И.А.) (имза)»;

Регламентка 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ай саен бирелә торган акчалата түләүне билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №____ бүлегенә

________________________________________

(муниципаль районында (шәһәр округында)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, ________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

түбәндәге адрес буенча яши:

______________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексы, телефоны, электрон почта адресы)

______________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ атальшы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы,

______________________________________________________________________

документны биргән орган атамасы)

техник хатаны төзәтүне сорыйм ________________________________________

______________________________________________________________________,

җибәрелгән (кирәклесе астына сызарга):

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында _______________

(карар датасы)

№______________ карарда.

(карар номеры)

айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында _______________

(карар датасы)

№______________ карарда.

(карар номеры)

Үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турындагы хәбәрне түбәндәгечә алуга риза:
язмача ____________________________________________
почта адресы буенча
түбәндәге телефонга смс-хәбәр итеп ____________________________________
телефон номеры
электрон документ формасында электрон почта адресы буенча ___________

Мөрәҗәгать итүче:_________________________ _________ «__»______ 20__ ел.
(Мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А.) (имза)»;

Регламентка түбәндәге эчтәлекле 6 нчы кушымта өстәргә:

«Ай саен бирелә торган акчалата түләүне билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Киңәш ителә торган форма

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №____ бүлегенә
_____________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар

№___________ «__» _____________

Мөрәҗәгать итүченең ФИА ______________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы ____________________________________________

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булу сәбәпле, айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатырга, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көннән дә артыграк чорга түгел

Бүлек җитәкчесе _____________ _______________
(Ф.И.А.) имза
мөһер урыны
Бүлек белгече _______________ _________________
(Ф.И.А.) имза

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):
язмача ____________________________________________
почта адресы буенча
смс-хәбәр белән ______________________
телефон номеры
электрон почта буенча ________________________________
электрон почта адресы

Бүлек белгече ___________________ ___________________
(Ф.И.А.) имза

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ бүлекчәсе
_________________________________________
(муниципаль районында (шәһәр округында)

Айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында карар

№___________ «__» _____________

Мөрәҗәгать итүченең ФИА ___________________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы _______________________________________________

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычларны җайга салу белән бәйле рәвештә, айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте «__» ________ күрсәтүне яңартып җибәрергә.

Бүлек җитәкчесе ______________ ________________
(Ф.И.А.) имза
мөһер урыны

Бүлек белгече ___________________ ___________________
(Ф.И.А.) имза
Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):
язмача ____________________________________________
почта адресы буенча
смс-хәбәр белән ______________________
телефон номеры
электрон почта буенча ________________________________
электрон почта адресы

Бүлек белгече ___________________ ___________________
(Ф.И.А.) имза».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Теркәлгән телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалану өчен бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү чыгымнарын каплау өчен субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 26 гыйнварындагы 47 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 07.09.2016 №513, 08.06.2017 №349, 23.05.2018 №392, 24.09.2018 №897, 04.02.2019 №77, 14.08.2019 №622, 14.11.2019 №1009, 08.05.2020 №289, 14.07.2020 №515, 08.10.2020 №709 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Теркәлгән телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалану өчен бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү чыгымнарын каплау өчен субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2 бүлектә:

2.4 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү бурычларны түләгәнчегә кадәр туктатыла, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көннән дә артыграк булмаган чорга гына.»;

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Банкта яисә башка кредит учреждениесендә ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.

2. Затның әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләренә каравын раслаучы документларның күчермәләре.

3. 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән хезмәт ветераннары, «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган затлар өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлегеннән үзләренең 2018 елның 31 декабренә федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүе турындагы белешмәне тапшыралар.

Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итүләрен раслый торган документны күрсәтә.

Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге хезмәткәре тарафыннан таныклана.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә мөмкин»;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара багланыш каналлары буенча вәкаләтле органнардан белешмәләр алына:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында;

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләү алудан баш тарту турында;

чыбыклы телефон элемтәсе булуы турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычлар булуы (булмавы) турында;

Нигезләмә кушымтасында төрләренең исемлеге күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Үзәк мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торганы да, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны»;

2.8 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булуы дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып тора.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

документлар белән әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;

әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән затларда чыбыклы телефон элемтәсенең булмавы;

әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән затларның Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында яисә федераль законнарда билгеләнгән башка нигезләр буенча, 63-ТРЗ номерлы законның 9 статьясы таләпләрен исәпкә алып, социаль ярдәм чараларын алуы;

гражданинның тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыруы;

мөрәҗәгать итүчеләрнең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча элемтә хезмәтенә субсидия билгеләү турында сорап мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынмаса»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «Нигезләмәнең 7.3 пункты» сүзләрен «Нигезләмәнең 7.6 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

3.1.1 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) элемтә хезмәтләре өчен субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында карар әзерләү;»;

3 бүлекнең 3.4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Элемтә хезмәтләре өчен субсидия билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаса, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне вәкаләтле органнардан сората:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләү алудан баш тарту турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычлар булуы (булмавы) турында;

Нигезләмә кушымтасында төрләренең исемлеге күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»

3.5-3.6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында карар әзерләү

3.5.1. Үзәк бүлеге белгече әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, алынган белешмәләр һәм әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда алынган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат вәкаләтләрен тикшерү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен кирәкле, әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентка 3, 6 нчы кушымталар нигезендәге формалар буенча электрон рәвештә элемтә хезмәтләре өчен субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яисә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын рәсмиләштерә;

элемтә хезмәтләре өчен субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын электрон рәвештә Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза кую өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган көннән ике эш көне эчендә, әмма гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: элемтә хезмәтләре өчен субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яки электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар проекты.

3.5.2. Үзәк бүлеге җитәкчесе элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар проектын карый һәм электрон санлы имза белән имзалап, Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура элемтә хезмәтләре өчен субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын имзалау җибәргәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: элемтә хезмәтләре өчен субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар.

3.5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында белдерү

Үзәк бүлеге белгече дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан элемтә хезмәтләре өчен субсидия билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карарга кул куйганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.5.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү яки элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү

3.5.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү туктатып торылган вакыт эчендә мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы турында белешмәләр алынса яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән бурычны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылган очракта, Үзәк бүлеге белгече:

әлеге Регламентка 6 нчы кушымта нигезендәге форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында карар проектын электрон рәвештә рәсмиләштерә;

әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә элемтә хезмәтләре өчен субсидия билгеләү турында карар проектын рәсмиләштерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү һәм элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләү турындагы карар проектларын имзалау өчен Үзәк бүлеге җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычның булмавы яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан бурычларны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү һәм элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләү турында карарлар проектлары.

3.5.4.2. Мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычларны җайга салмаган очракта, элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләү турында гариза биргән көннән соң 90 көн узгач, Үзәк бүлеге белгече компенсация билгеләүдән баш тарту турында карар проектын әзерли һәм Үзәк бүлеге җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләү турында гариза биргән көннән соң 90 көн узгач, аннан соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләүдән баш тарту турында карар проекты.

3.5.4.3. Үзәк бүлеге җитәкчесе дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында һәм элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләү турында карар проектларын яисә элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләүдән баш тарту турында карар проектын карый һәм электрон санлы имза белән имзалый һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

